Гыйбадуллина, Л. "Язудан туеп, төн уртасында стадионга чыгып йөгерергә мөмкинмен" / Л. Гыйбадуллина; [әңгәмәдәш] А. Гайнуллина // Акчарлак. – 2025. – №10 (12 март). – Б. 2-3

**Актанышлылар шундый инде алар: сүзгә тапкыр, үткен, булдыклы. Лилия Гыйбадуллина (Сираева) да шушы яклар һавасыннан илһам алган, чишмә суларын эчеп үскән шагыйрь. "Шагыйрә" дигәнне яратмый. "Шигъриятне җенескә дә бүлмибез, торак пунктка да бәйләмибез", – дип каты тора. Башка мәсьәләләрдә дә үз фикерен кыю белдерә, үзенә генә хас "егетлеге" иҗатында да чагыла.**



# Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА: "Язудан туеп, төн уртасында стадионга чыгып йөгерергә мөмкинмен"

**– Лилия, син бунтарьмы?**

– Кирәк чакта. Гаделсезлекне кабул итмим. Сабыр кеше түгелмен. Әмма конфликтлардан качам. Ул энергияне, көчне суыра торган әйбер. Шул бунтарьлыктан шигырь барлыкка киләдер. Үзгәрешләр чорында, ниндидер кысынкылык, киеренке халәттә мәйданга яхшы шигырьләр туа. Шуңа күрә мин бүгенге татар шигъриятен дә югары бәялим.

**– "Укырлык әйбер юк, чүп белән тутырдылар" диләр тагын.**

– Чүп өскә калка, аралый белергә кирәк. Китапханәләрдән асыл шигырьләрне эзләп табып була.

**– Әдәбиятта тормышның чынбарлыгын чагылдыруга карашың нинди?**



"Ирем Илһам һәм улларыбыз Ильяс, Закир белән".

– Әдәбият – дөньяның көзгесе бит ул. Ә бездә татарча икән, читекле, калфаклы булсын! Әйтик, Шекспир трагедияләрендә ни генә юк. "Бездә алай булмаган" дип чирканып тормаган. Булгаковны алыйк, Чеховны. Бездә дә булган андый әсәрләр, Гаяз Исхакый язган, Галимҗан Ибраһимов. Саллы каләмле шәхесләр бу проблеманы милли җирлеккә бүлмичә, кеше психологиясенә бәйләп ачып бирә белгәннәр. Әмма аларга соңыннан буржуаз әдәбият дигән тамга тагылган. "Безнең колхозда бар да әйбәт..."

**– Хәзер без яшәгән чор, бүгенге көн бөтенләй сурәтләнми кебек.**

– Журналистикада да сизелә ул. Шигырьдә бүгенге көн белән үткәннәр, киләчәк һәрвакыт кисешә, образларга төрелеп бирелә. Ә прозада катлаулырак. Аннары әсәрләрне халыкка таныту эше дә аксый, җайга салынмаган.

**– Язучы үзен үзе танытмаса, бу эшне кем башкарырга тиеш?**

– Язучының бу эшкә энергиясе, вакыты җитәрлек булса ярый да. Бу эш кирәктер, социаль челтәрләрдә дә активлык кирәк. Әмма идеаль вариантта язучының төп эше язу булырга тиеш. Калганы аны борчырга тиеш түгел. Китабы сатыламы, укыламы, бу мәсьәлә язучыдан башка җайга салынган булырга тиеш. Моның белән шөгыльләнергә авторның агенты, менеджеры булырга тиеш.

**– Синең шундый агентың бармы?**

– Юк шул. Безнең илдә язучы дигән һөнәр дә юк бит. Язучылар көндез кайдадыр эшли һәм төнлә, эштән буш вакытында гына язалар.

**– Син дә журналист булып эшлисең, ирең, улларың бар. Шуннан тыш очрашуларда районнарда йөрисең, Казанда**



2011 ел. "Кадерле әти-әниләребез".

**чараларда катнашасың. Әле спектакль чыгарасың син, әле фильм төшерәсең. Кайчан язасың?**

– Миңа шулай яшәү ошый. Мин язучы дип айлар, атналар буе өстәл артында гына да язып утыра алмыйм. Бүген Казаннан кайтып, иртәгә авылда мал суешып, эчәге юып йөри алам. Шуннан ялт кына җыенып берәр мәктәпкә әдәби очрашуга китәм. Бер-ике көн компьютерга капланып язып утырам аннары. Язудан туеп, төн уртасында стадионга чыгып йөгерергә мөмкинмен. Шулай йөргәндә генә чын тормышны күрәсең, татар теленең кирәкле булуына инанып, куанып кайтасың.

**– Татар теленең кирәксезлеге дә сизеләме?**

– “Тел бетә”, “телнең киләчәге юк” дип чаң кагалар бит. Бигрәк тә Казанга берәр тапшыруга килсәң, “балалар татарча белми, безнең тел беркемгә дә кирәк түгел” дип хәсрәткә батып утыралар. Район мәктәпләрендә, мисал өчен, Мөслимдә яки Әгерҗенең Кадыбаш авылында саф татарча аралашкан балалар белән очрашудан кайтып, моны тыңлавы авыр. Редакциядән чыкмаган журналист туган телен “үтергән, ясин чыккан” инде. Үзебезнең Актаныш балалары бу тапшыруларны күрмәсә генә ярар иде, дим.

**– Язучылар берлеге эшчәнлегеннән канәгатьме син?**

– Алар чынлыкта күп эш башкаралар. Тәрҗемәчелек эшчәнлеге көчле, үзенең “Язучы” дигән нәшрияты барлыкка килде. Мисал өчен, минем “Дәвамы бар” һәм “Идегәй” дигән китапларым шунда чыкты. “Идегәй” дастанын балалар яратып уйный торган компьютер уены форматында эшләдем. Аны Наил Ишмөхәммәтов рус теленә дә тәрҗемә итте. Берлекнең башкарган эше күп, әмма ул күренми, һаман шул халыкка җиткерү мәсьәләсе аксый. Зарланучылар да бардыр, без зарланырга ярата быз бит. Ө тотып эшләргә атлыгып торучылар аз. Язучылар очрашуларга йөрергә яратмый, эш кушарга кеше юк.

**– Бәйгеләр, грантлар турында мәгълүмат ничек таратыла?**

– Грантларны Мәдәният министрлыгы игълан итә. Язучылар берлеге, министрлык сайтларын күзәтеп барырга кирәк. Үпкәләп, кемнедер гаепләп утырасы түгел, язарга кирәк. Бөтен нәрсәгә рәнҗеп яткан кешенең күңелендә иҗат итәрлек, каләмгә төшерерлек яктылык кала микән?

**– 2022 елда ТР Президенты карамагындагы Татар телен саклау комиссиясе инициативасы белән оештырылган ябык әдәби конкурста дүрт номинациядә җиңеп, ярты миллион сумнан артык приз откач, Лилия: “Мин җиңәргә калгач, әдәбиятыгыз шул чама гына икән”, – дигән дип язып чыктылар. Чынлап та шулай әйттеңме?**

– Алай каты әйтмәдем инде. Ркаил абыйга: “Мин татар шигъриятенең бүгенгесе турында югарырак фикердә идем”, – дидем. Күбрәк укыган саен, үзеңнең әдәби яктан камил түгеллегеңне, аз эшләгәнеңне аңлыйсың. Бәйге нәтиҗәләренә мин чынлап та гаҗәпләндем. Дүрт номинациядә беренче урын алгач, аптыраганмындыр инде.



2022 ел. “Бәйге нәтиҗәләренә чынлап гаҗәпләндем”.



**БЕЛЕШМӘ:**

*Лилия Фаис кызы Гыйбадуллина Актаныш районы Әҗмәт авылыннан. Лилиягә 37 яшь, туган көне 22 мартта. Татарстан язучылар берлеге әгъзасы. Кияүдә, Ильяс һәм Закир исемле уллары бар.*

**– Язучылар арасында көнчелек зур, диләр. Син аны тоясыңмы?**

– Төрлесе булды. Төртмә сүзләр, гайбәт, көнчелек, гаепләүләр – алар бөтенесе дә түбән энергия. Рухың белән алардан өстенрәк булсаң, сиңа бу сүзләрнең бер зыяны да килми. Бер дустым шулай диде, мин бу сүзләрне көн саен диярлек искә төшерәм. Үз-үзеңне пычраклыктан сакларга кирәк.

**– Син иҗат эшен әллә ничә тапкыр “юлерлек” дип атадың инде. Үзеңнең юләрлекләрең нәрсәдә чагыла?**

– Кешегә тулы канлы тормыш, бәхет өчен адреналин кирәк. Кемдер аны спорттан ала, мин – иҗаттан. Язучы кешене хыялый, һавалы, диләр. Әмма мин реалист, җир кешесе. 2010 елда Казаннан Чаллыга кайтып киттем. “Кияүгә чыгам, үземне гаиләгә багышлыйм, иҗат белән шөгыльләнмим, җитте”, – дидем. Ике малай туды. Бераз башкарма комитетта тәрҗемәче булып эшләп алдым. Ильяс улыма алты яшь тулгач, мәктәпкә “шпион”лыкка киттем. Ике ел татар теле укытып карадым. 2017 ел, атна саен программа үзгәрә, мәктәпләрдә прокуратура йөреп тора, төрле провокацияләр, “татар теле миңа нигә кирәк?” дигән балалар. Аннан соң мине Факил абый Сафин “Көмеш кыңгырау”га, “Мәйдан”га чакырды. Анда балаларның татарча язган хатларын күреп, күңелләр күтәрелде.

**– Синең үз илһамың бар – ирең Илһам. Ул нинди?**

– Һәйкәл куярлык кеше ул. Югары белемне татар телендә алган, автомеханика факультеты тәмамлаган чын татар егете. Мин ир кеше булсам, аның кебек яхшы ир була алмас идем. Аллага шөкер, ул мине аңлый. Күңелемдә йөрткән борчуымны аңа сөйлим, аның җилкәсенә башымны куеп елый алам, бары аңа гына ачыла алам, серләрем аңа гына сыя.

**– Гадәттә, “ireңә бөтен нәрсәне дә сөйләп бетермә” диләр. Синең бер сереӊ дә калмыймы?**

– Кала, әлбәттә. Иҗатымда язылганнар аның өчен сер. Чөнки ул мин язганнарны укымый. Очрашып йөргән вакытта шигырьләремне укып карады да “нәрсә соң бу?” диде, аңламады. Шуннан соң укыганы юк.

**Альбина ГАЙНУЛЛИНА**